# Онытылып барган уеннар



“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының мәгариф бүлеге”
муниципаль казна учреждениесе

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә
бюджет белем бирү учреждениесе

**Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче тәрбиячеләр өчен**

**методик ярдәмлек**

# ОНЫТЫЛЫП БАРГАН УЕННАР






**Биектау - 2022**

[illegible] балалар” берәм «кәлүк»кә таяк ыргыталар , аны очыралар. Таякларын «кәлүк»кә тимәгән балалар, «кәлүк» очкан вакытта, тиз генә таякларын барып алалар. Вакытында үз урынына кайтып җитә алмасалар, көтүче, «кәлүк»не урынына куеп, кайтып җитмәгән баланың исемен әйтеп кычкыра. Ул баланы көтүче итеп куялар.

**“МАК” уены**

Җиргә төрле урынга 1 дән 10 га кадәр саннар язылган шакмаклар ясала. Яссы таш (элек конфетлардан бушаган тимер түгәрәк савытлар алганнар) алып, бер аякта сикереп ташны саннар буенча дөрес итеп шакмактан шакмакка күчереп барырга кирәк. Кем шакмактан чыкмый, дөрес алып бара, шул җинүче.





**“АТЫП ЧЫГАРЫШЛЫ” уены**

Ике уенчы капма-каршы баса. Аларның максаты - урталагы бер төркем уенчыларга туп тидерү. Ә урталагылар туптан качарга тиешләр. Очып барган тупны тота алганга бер балл языла. Димәк, бер тапкыр туп тисә дә, ул әле уенда кала дигән сүз. Ахырдан уртада бер генә уенчы калгач, аңа ничә яшь, туп атудан шул кадәр сакланырга тиеш булачак. Эләктерсә – җиңелә



# Методическое пособие предназначена для детей дошкольного и школьного возраста . Рекомендуется для учителей начальных классов, для педагогв ДОУ для родителей

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы  башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә  бюджет белем бирү учреждениесе тарафыннан бастырылган “Онытылып барган уеннар” җыентыгына

бәяләмә

Уен – бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз бер өлеше. Тәрбия чарасы буларак, ул балаларның камилләшүенә, шәхес буларак формалашуына, үзгәрүенә этәргеч булып тора. Балага белем һәм тәрбия уен аркылы яхшырак бирелә. Ул уйнаган вакытта бик күп нәрсәләрне таный, үзенә күнекмәләр ала. Уен формасында оештырылган эшчәнлекләр кызыксынуны көчәйтә, баланың мөстәкыйльлеген үстерә.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә туган телгә өйрәнүдә уен куллануның күпьеллык практикасы бар. Педагог тарафыннан дөрес оештырылган уеннар гына балаларның акыл үсешенә уңай йогынты ясый. Шунлыктан педагогның һәр төркемгә куелган тәрбия бурычларын, балаларның яшь үзенчәлекләрен, һәр уенның эчтәлеген һәм аны үткәрү методикасын яхшы белүе сорала.

Һәркемнең балачагы, яшьлеге бар. Һәм кем генә шул балачак елларын искә төшерми икән?  Балачак еллары күңелле мизгелләр булып артта калалар. Балачакта уйнап үскән уеннар әкренләп онытыла бара, аларны бүгенге заман уеннары алыштыра. “Онытылып барган уеннар” җыентыгы бүгенге көннең көн кадагында торган мәсьәләне күздә тотып төзелгән. Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы педагоглары тарафыннан элеккедән калган уеннарны җыеп , яңарту төп максат итеп куелган.

Элеккеге вакытта уйналган күп уеннарның бүгенге көндә әһәмияте кимеде, күбесен балалар да, әти – әниләр дә белми. Шуларны истә тотып, җыентыкта төрле елларда уйналган, элекке вакыттагы уеннар кергән. Аларны яңартып, балалар бакчалары педагогларына, мәктәп укытучыларына  җиткерү өчен бу җыентык иң кулай методик ярдәмлек дип санала.

Гомумән алганда, бу җыентык мәктәп укытучылары өчен дә, балалар бакчалары педагоглары өчен дә бик кызыклы, заманча зәвык белән эшләнелгән эшкәртмә буларак тәкъдим ителә.

Казан федераль университетының
татар теле белеме кафедрасы доценты,
филология фәннәре кандидаты — Г.К.Һадиева

МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ФГАОУ ВО «КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»
ОГРН 1021602841391 ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ
ПОДПИСЬ Хадиевой Г.К.
Документовед

# Рецензент : кандидат филологических наук, доцент Казанского Федерального университета Хадиева Г.К.